ПӘНҖЕШӘМБЕ
28
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 22 (6744)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) нын ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ

МОСКВА, КРЕМЛЬ, ИПТӘШ СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Смоленск өлкәсенең азат ителгән һәм вакытлыча оккупацияләнгән районнарындагы хезмәт ияләренә Сезнең телеграммагыз һәм Кызыл Армиянең рәхмәте аларда тагын да зуррак патриотлык хисе һәм үз ватаннарына, Сезгә, бөек Ленин эшен дәвам иттерүчегә тагын да зуррак мәхәббәт хисе тудырдылар. Кешелек дөньясының иң явыз дошманы—немец фашизмы өстеннән героик Кызыл Армиянең, Сезнең, иптәш Сталин, зирәк җитәкчелегегездә ирешкән яңа җиңүләре белән рухланып, безнең өлкәбезнең азат ителгән районнарындагы хезмәт ияләре үзләренең саклык акчаларыннан, моннан элек банкка кертелгән 6.702.980 сум өстенә, «Смоленск партизаны» исемле танклар колоннасы төзелешенә 6.783.020 сум акча җыйдылар һәм Дәүләт банкысына керттеләр. Өстәмә рәвештә илнең оборона фондына 210.000 сумлык дәүләт заемнары облигацияләрен тапшырдылар. Смоленск партизаннары, 1.400.000 сумнан тыш, өстәмә рәвештә, өлкәнең вакытлыча оккупацияләнгән районнарындагы хезмәт ияләре арасыннан 132.000 сум акча җыеп Дәүләт банкысына тапшырдылар һәм 170.000 сумлык дәүләт заемнары облигацияләре җыйдылар. Өлкәнең хезмәт ияләре оборона фондына өстәмә рәвештә 14.906 пот ашлык, 7.106 пот печән, 2.000 данә эре һәм вак тире, 854 килограмм йон тапшырдылар. Танклар колоннасы төзелешенә барлыгы 15.018.000 сум акча һәм 7.221.000 сумлык дәүләт заемнары облигацияләре җыелып Дәүләт банкысына тапшырылды. Танклар колоннасына һәм илнең оборона фондына өлкәдә барлыгы 22.239.000 сум җыелды.

Өлкәнең азат ителгән һәм вакытлыча оккупацияләнгән районнарындагы хезмәт ияләре «Смоленск партизаны» исемле танклар колоннасы төзелешенә һәм илнең оборона фондына акча, ашлык һәм башка продуктлар җыюны дәвам иттереп, героик Кызыл Армиябезгә ярдәм күрсәттеләр һәм гитлерчы юлбасарларны тәмам тар-мар иткәнчегә кадәр бу ярдәмне күрсәтерләр.

Өлкәбездәге барлык хезмәт ияләре исеменнән сәлам һәм озак елларга сәламәтлек һәм озын гомер теләвебезне кабул итегез, иптәш Сталин.

ВКП(б) нын Смоленск Өлкә Комитеты секретаре **ПОПОВ.**

ВКП(б) НЫҢ СМОЛЕНСК ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ ПОПОВКА

Смоленск өлкәсенең азат ителгән һәм вакытлыча оккупацияләнгән районнарында, моннан элек җыелган 14.952.980 сум өстенә тагын танклар колоннасы төзелешенә һәм илнең оборона фондына 7.286.020 сум акча җыйган һәм оборона фондына өстәмә рәвештә 14.906 пот ашлык һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары керткән хезмәт ияләренә минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

СТАЛИНАБАД
ТАҖИКСТАН КП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ ПРОТОПОПОВКА
ТАҖИКСТАН ССР СОВНАРКОМЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ КОРБАНОВКА
ТАҖИКСТАН ССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ ШАГАДАЕВКА

Таҗикстан Совет Социалистик Республикасынын «Таҗикстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә беренче 67 миллион сумнан тыш өстәмә рәвештә 14 миллион сум җыйган, ССР Союзы оборона фондына һәм республикадагы шәһәрләрнең хезмәт ияләре өчен азык продуктлары тапшырган хезмәт ияләренә минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Верховный Баш Командующийның Приказына җавап итеп

ЧИСТАЙ, 27 январь. **(Телефон буенча).** Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның Приказы уңае белән, районның барлык колхозларында митинглар булып үтте. Митингта катнашучы колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар:—Без туган илебез өчен, героик Кызыл Армиябез өчен бөтен ярдәмне күрсәтергә әзер торабыз, дип белдерделәр.

«Доброволец» колхозында үткәрелгән митингка 220 дән артык кеше катнашты. Алар, ике көн эчендә самолетлар эскадрильясе төзү фондына 72 мең сум средство җыеп тапшырдылар. Колхоз председателе иптәш Юсупов 20.000 сум, яшелчә бригадиры иптәш Кокушкин 3.000 сум һәм тимерче Карачев 2.000 сум акча бирделәр. «Кама» колхозы председателе Мясников 5.000 сум, «Красный луговик» колхозы членнары Гурьянова, Авирьянов иптәшләр 10 ар мең сум акча һәм Голяков бер сарык һәм бер тана бүләк иттеләр. Шул ук колхозның ат караучысы иптәш Дорофеев бер сарык, 2.000 сум акча, иптәш Рыжов бер сарык һәм 1.000 сум акча бирделәр.

«Бахта» колхозында да самолетлар эскадрильясе төзүгә средство туплау зур активлык белән бара. Колхоз председателе Чернов һәм ат караучы Исаев иптәшләр 5.000 әр сум средство керттеләр. Молотов исемендәге колхоз членнары да алардан калышмадылар. 75 яшьлек Иван бабай Гошинин митингта: «Без, батыр һәм куркуны белмәүче сугышчыларга бер нәрсәне дә кызганмабыз, кулыбыздан килгән бөтен ярдәмне күрсәтергә әзер торабыз»,—диде һәм шунда ук ул танклар колоннасы төзүгә 1.500 сум акча, 150 килограмм ашлык бүләк итте.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Төньяк-көнбатыш фронт). Н-че авиачастьның очучы-истр бителе капитан Хәсән Ибәтуллин ватан сугышы вакытында күп фронтларда булды һәм 278 сугыш чан очышта катнашты. Һава сугышларында ул бер үзе 8 немец самолетын, иптәшләре белән берлектә 3 немец самолетын бәреп төшерде. Тәҗрибәле һәм куркусыз очучы буларак, капитан Ибәтуллин Н-че авиачастьның штурманы итеп билгеләнде. Һава сугышларында батырлык һәм куркусызлык күрсәткән өчен татар халкының турылыклы улы Хәсән Ибәтуллин Ленин ордены һәм Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.

ТАСС фотохроникасы

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

27 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

27 нче январьга каршы төндә **Көньяк Көнбатыш, Көньяк, Төньяк Кавказ, Воронеж, Волхов һәм Ленинград** фронтларындагы безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Дон фронты гаскәрләре Сталинград районында чолганып алынган немец фашист гаскәрләрне бетерү буенча сугышлар алып бардылар. Н-че часть сугышчылары немецларның 669 нчы пехота полкы подразделениеләрен һәм штабын бөтенләй юк иттеләр. Немецларның 534 нче пехота полкы тулы составы белән пленга бирелде.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре һөҗүмне җәелдерүдә дәвам иттеләр һәм көчләренең бер өлеше белән дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Н-че гвардия часте халык яши торган бер пунктган немецларны бәреп чыгарды һәм 3 самолет, 4 мең авиабомба, бензин тутырылган 200 мичкә, 37 орудие, 54 пулемет, танкка каршы ата торган 24 мылтык, 5 тягач, бик күп азык һәм башка трофейлар кулга төшерде. Немецларнын 300 дән артык солдат һәм офицеры плен алынды. Икенче бер участокта безнен подразделениеләр дошманның контратакасын кире кайтардылар һәм немецларның 2 ротага якын пехотасын юк иттеләр.

* * *

Көньяк фронтта Н-че часть сугышчылары халык яши торган бер пункт өчен барган бик каты сугышта немецларның 200 дән артык солдат һәм офицерын кырып ташладылар һәм дошманның 2 танкысын җимерделәр. Икенче бер участокта безнең укчы берләшмәбез немецларның каршылык күрсәтүен җимерде һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алды. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошманның тар-мар ителгән частьларыннан чолганып алынган берничә группа көнбатышка таба үтеп чыгарга маташканнар иде. Озакка бармаган сугыштан соң дошман коралын ташлады. Немецларның 1.463 солдаты һәм офицеры плен алынды. Икенче бер участокта Н-че берләшмә халык яши торган берничә пунктны алды. Бик күп трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре уңышлы рәвештә алга бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Армавир районында Н-че берләшмә частьлары түбәндәге трофейларны кулга төшерделәр: 200 гә якын орудие, 137 миномет, 127 пулемет, 2 000 винтовка, 229 автомат, танкка каршы ата торган 263 мылтык, 2.000 снаряд, 8 000 авиабомба һәм 2 склад авиабомба, 100.000 патрон һәм сугыш припаслары һәм төрле хәрби милекләр саклана торган берничә склад. Икенче бер участокта совет танкистлары немецларның бер батальонын тар-мар иттеләр. Сугыш кырында дошманның 400 гә якын үле гәүдәсе калды. Немецларның 120 солдат һәм офицеры плен алынды.

* * *

Карел-Фин ССР да хәрәкәт итүче партизаннарның 3 отряды январь урталарында бер үк вакытта дошманның халык яши торган 3 пунктка урнашкан гарнизоннарына һөҗүм ясаганнар. Совет патриотлары дошманның 200 гә якын солдат һәм офицерын кырып ташлаганнар, 5 орудиене, 3 минометны, 2 радиостанцияне, прожектор установкасын юк иткәннәр, сугыш припаслары һәм азык саклана торган берничә складны шартлатканнар һәм яндырганнар.

* * *

Воронеж өлкәсенең Гартмашевка станциясендә немец-фашист кабахәтләрнең канлы җинаятьләре турында түбәндә акт китерелә: «Немецлар чигенү алдыннан тимер юл эшчеләренең бер группасын хатыннары һәм балалары белән бергә тулай торакка куып керттеләр һәм аларны ерткычларча җәзаладылар. Гитлерчы палачлар сигналист Дмитрий Косоговны, аның хатынын, 2 кызын һәм баласының балаларын—3 яшьлек Николайны һәм яшь ярымлык Валентинаны, сигналист Петр Ткачевны, аның хатынын һәм улын, сигналист Федор Чесноковны, аның хатынын һәм 4 яшьлек кызын үтерделәр. Гартмашевка станциясендә торучы халыклардан 20 кешелек икенче бер группаны фашист ерткычлар тимер юл будкасына куып керттеләр һәм анда аларны атып үтерделәр». Актка кул куйдылар: Л. Гончарова, О. Слюсарева, Е. Янголенко, П. Королева, Е. Шевцова һ. б.



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Төньяк Кавказ). Краснодар краеның Чамлыкская станицасыннан 60 яшьлек казак Пазел Гаврилович Камнев үзенең ике улы белән бергә фронтка китте. Сугышта күрсәткән батырлыгы өчен Ленин ордены белән бүләкләнде. Рәсемдә: П. Г. Камнев.

ТАСС фотохроникасы.

Сугыш самолетлары эскадрильяләрен күбрәк бирик!

ЯҢА АВИАЭСКАДРИЛЬЯЛӘР ТӨЗҮ ӨЧЕН

Героик Кызыл Армиягә сугыш машиналарын тагын да күбрәк җитештерү өчен илебезнең хезмәт ияләре кулларыннан килгән бөтен ярдәмне күрсәтәләр. Яңа танк колонналары, авиаэскадрильяләр һәм башка сугыш машиналары төзү фондына средстволар туплау гаять зур күтәренкелек белән дәвам итә.

Яңа авиаэскадрильяләр төзү өчен соңгы берничә атна эчендә Казан шәһәренең Бауман районы хезмәт ияләре 4 миллион 560 мең сум акча туплап тапшырдылар. Шул исәптән Татарстан НКВД работниклары 1 миллион 400 мең сум, 1 нче тегү фабрикасының эшчеләре һәм хезмәткәрләре 102 мен сум, проект-монтаж конторасы работниклары 60 мең сум бүләк иттеләр.

* * *

Татарстан сәнгать идарәсе работниклары яңа авиаэскадрильяләр төзү фондына 100 мең сум, Сталин премиясе лауреаты, орденлы композитор Д. Покрасс җитәкчелегендәге тимер юл джаз оркестры артистлары 50 мен сум акча туплап тапшырдылар. Шәһәрнең барлык предприятиеләрендә, учреждениеләрендә һәм оешмаларында средстволар туплау дәвам итә.

* * *

Татарстан фәнни көтепханәсе работниклары Кызыл Армия өчен яңа сугыш машиналары төзү фондына 4.100 сум акча бүләк иттеләр һәм Татарстанның барлык көтепханә работникларын үзләре белән тиңләшергә чакырдылар.

САМОЛЕТЛАР ТӨЗҮГӘ

Бөек юлбашчының котлавы Биектау районы хезмәт ияләрен бик шатландырды. Алар самолетлар эскадрильясе төзүгә тагын да активрак катнаша башладылар.

Вахитов исемендәге авыл хуҗалыгы артеле колхозчылары элек 68.000 сум средство туплап тапшырганнар иде инде. Алар тагын 20.000 сум акча җыеп бирделәр. Биектау районы сельпосының членнары 38.500 сум акча җыеп тапшырдылар. Самолетлар төзү фондына акча кертү дәвам итә.

Д. СКВОРЦОВ.

ФРОНТТАГЫЧА ЭШЛИЛӘР

Чистайдагы механика заводы эшчеләре, инженер-техник работниклары, героик Кызыл Армиябезнең һөҗүмне җәелдереп көннән-көн алга баруы һәм дошманны тармар итүе белән шатланып, производствода эшләп чыгаруны берничә тапкыр арттыру өчен көрәшәләр. Агач эшкәртү цехында эшләүчеләрдән Галләмов, Гыйбадуллин, Шахмаев һәм Козлов иптәшләр, фронт заказларын срогыннан алда үтәп, көнлек норманы системалы рәвештә 150—170 процент итеп үтиләр. Пенкин, Семенов иптәшләр дә норманы 250—300 процентка кадәр җиткереп үтиләр. Бу цехта 32 кеше көнлек нормаларын 170—240 процентка үти.

К. ШАКИРОВ.

Н-че завод эшчеләренә бүләкләр

ТЕЛӘЧЕ, 27 январь. (Телефон буенча). «Чулпан № 2» колхозы колхозчылары Казандагы Н-че завод эшчеләренә һәм госпитальләрдә дәваланучы сугышчыларга төрле авыл хуҗалыгы продуктлары җыеп җибәрү эшен башлап җибәрделәр. Алар бер көн эчендә генә дә 40 тавык, 15 каз, бик күп бәрәңге һәм башка продуктлар җыеп тапшырдылар.

Бу хәрәкәт башка колхозларда да башланды. «Красный сад» колхозы членнары 50 килограмм ит, 1 центнер бодай оны, Молотов исемендәге колхоз членнары 50 килограмм ит, 5 килограмм бал җыйдылар.

Бу продуктлар 28 нче январьда, кызыл олаулар белән, шәһәргә, заводка озатылачаклар.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ПАРТИЯ САФЛАРЫН ҮСТЕРҮ БЕЛӘН ҖИТДИ ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ

ВКП(б) ның Алексеевский райкомы 1942 нче елда партия сафларына 68 кешене кабул итте.

Районның иң алдынгы кешеләре ВКП(б) сафларына керергә омтылалар. Менә «Восход» колхозының кошчылык фермасында эшләүче иптәш М. Тюлянина. Ул җитәкчелек иткән ферма район күләмендә иң алдынгы булып санала. Бу фермада производство планнары һәрвакыт арттырып үтәлеп бара. Иптәш Тюлянина үрнәкле эшләве өчен берничә тапкыр бүләкләнде. Күптән түгел генә ул, партия сафларына кабул ителде.

Старая Таганская авылы башлангыч партоешмасы соңгы вакытта үз сафларына 6 кешене кабул итте. Алар арасында дәүләткә ашлык тапшыру эшендә үрнәкле эшләүче, алдынгы агитатор Фәтхетдинова, ватан сугышыннан кайткан Муртазин иптәшләр дә бар.

Ләкин шуны әйтергә кирәк, кайбер башлангыч партоешмалар ВКП(б) сафларын үстерү мәсьәләсе белән җитәрлек шөгыльләнмиләр. Райондагы 32 партоешмадан 12 сенең ел буена бер генә кеше дә кабул итмәве моны ачык күрсәтә. Рамазановская авылы партоешмасы (секретаре иптәш Дубровин), Караваевская авылы партоешмалары (секретаре иптәш Лебедева) 1942 нче елда бер генә кеше дә кабул итмәгәннәр.

Районда партия сафларына яңа кабул ителгән иптәшләр белән эшләү дә һич тә канәгатьләнерлек түгел. ВКП(б) райкомы пленумының бу турыдагы карарын күп кенә партоешмалар үтәмәгәннәр. Партия сафларына яңа кабул ителгән иптәшләр өчен 15 урында агымдагы политика түгәрәкләре оештырылган булган. Ләкин аларның берсе дә дип әйтерлек системалы рәвештә эшләмиләр. Мәсәлән, «Красный Восток» совхозы, «Сухое молоко» заводы, «Ударный труд» артеле партоешмалары янында оештырылган түгәрәкләр 4 айдан бирле бер тапкыр да занятие үткәрмәгәннәр.

Ватаныбызга чын күңелдән бирелгәнлекләрен эштә күрсәткән алдынгыларны ВКП(б) сафларына тарту өчен башлангыч партоешмалар һәм ВКП(б) ның Алексеевский район комитеты җитди шөгыльләнергә тиеш.

М. ФЕДОРОВ.

ЭШ БЕЛӘН ҖАВАП БИРӘЛӘР

«Светоч» фабрикасы янындагы партоешма эшчеләр, инженер-техник работниклар һәм хезмәткәрләр арасында агитация-масса эшләрен киң җәеп җибәрде. Агитаторлар барлык цехларда да ватан сугышы фронтындагы уңышлар турында системалы рәвештә беседалар үткәрәләр. Совет Информбюросы белдерүләре, сугыш эпизодлары һәм партиябез, хөкүмәтебезнең карарлары турында аңлаталар. Кычкырып газета укулар оештырыла һәм стена газеталары чыгарыла. Масса-аңлату эшләре коллектив алдында торган практик бурычлар белән нык бәйләп алып барыла.

Большевистик агитациянең гүзәл нәтиҗәләре бар, әлбәттә. Эшчеләр коллективы Кызыл Армиябезгә ярдәм итүне тагын да көчәйтергә, январь ае планын 24 нә үтәп чыгарга йөкләмә алганнар иде. Алар аны уңышлы үтәделәр. Фабрика буенча айлык план 16 нчы январьга үтәлде. Алдынгы стахановчылардан Борһанов, Жарков һәм башка иптәшләр нормаларын 200 процент һәм аннан да артыграк итеп үтәделәр.

Шулай ук, фабрика коллективы кыска гына вакыт эчендә самолетлар эскадрильясе төзү һәм батыр сугышчыларга бүләкләр алу өчен 49.400 сум средство җыеп тапшырды. Байтак кына эшчеләр самолетлар эскадрильясе төзү фондына берайлык һәм ике айлык хезмәт хакы күләмендә акча керттеләр. Бу эштә дә коммунистлар һәм комсомолецлар үрнәк күрсәттеләр. Мәсәлән, иптәш Шакирова ике айлык, Логинов, Сергеев, Герасимова, Степанова һ. б. иптәшләр һәрберсе берәр айлык хезмәт хакы күләмендә средство тапшырдылар.

Г. ФАЗУЛЛИНА.

Комсомолецлар хәрби белемне үзләштерәләр

Чүпрәле районы комсомолецлары һәм союздан тыш яшьләре хәрби белемне зур кызыксыну белән үзләштерәләр. Занятиеләргә төгәл йөриләр, дисциплиналылык үрнәкләре күрсәтәләр.

Комсомолецларның күпчелеге, всевобуч программасын тәмамлаганнан соң сынауларны отлично һәм яхшы билгеләренә тапшырдылар. Андыйлардан Гафаров, Долгов, Фәйзуллин, Низамов, Чучков һ. б. иптәшләрне күрсәтергә мөмкин.

Всевобучка йөрүчеләр чаңгы спортын аеруча яхшы үзләштерделәр. Хәзер яшьләрдән 318 кеше чаңгычылар булып әзерләнделәр инде.

Шулай ук комсомолецлар, союздан тыш яшьләр оборона фондына, танклар колоннасы төзелешенә средстволар туплауда алдынгы оештыручылар булдылар.

Комсомолецларның бу активлыгын ныгыту буенча ВЛКСМ ның район комитеты тагын да җитди шөгыльләнергә тиеш.

П. ДАНИЛОВ.

ВКП(б) нын ШӘҺӘР КОМИТЕТЫНДА

ВКП(б) нын Казан Шәһәр Комитеты бюросы, ВКП(б) Өлкә һәм шәһәр комитетларының фронтовиклар семьяларына материаль ярдәм итү турында берничә тапкырлар күрсәтүләрен үтәмәгән өчен һәм хәрби хезмәткәрләр семьяларының жалобаларына бюрократларча караганы өчен хезмәт ияләре депутатларының Сталин район советы башкарма комитеты председателе М. П. Панниковны эшеннән алырга һәм аны ВКП(б) сафларыннан чыгарырга карар бирде.

ДОШМАННЫ КЫРЫП ҺӘМ ҖИМЕРЕП АЛГА БАРУЧЫ КЫЗЫЛ АРМИЯБЕЗГӘ ТЫЛНЫҢ ЯРДӘМЕН ТОРГАН САЕН АРТТЫРЫЙК!

Бер кешегә 8 профессия

3 нче номерлы фанера заводында иптәш Морозов җитәкчелек итә торган бер цех бар. Бу цех өстенә гаять универсаль бурыч йөкләнгән: ул, моментның таләп итүенә карап, бик күп төрле эшләр башкарырга һәм үзенең эшен бик еш һәм тиз рәвештә үзгәртеп корырга тиеш. Зур оперативлык таләп итә торган мондый шартларда эшләү өчен цех карамагына иң кыйммәтле кешеләр— төрле профессияләрне үзләштергән эшчеләр бирелә. Мәсәлән, Сәйфетдинов, Зинин, Иваницкий иптәшләр бер үк вакытта столяр да, токарь да булып эшлиләр. Иптәш Иваницкий исә болар өстенә радио-телефон техникасын да шактый яхшы белә. Пычкы кайраучы Анна Чебурахтина шорник булып та эшли һәм шулай ук циркуль станогы белән дә бик яхшы таныш.

Семен Егоров төп профессиясе буенча фрезеровщик. Ләкин ул моннан башка 5—6 төрле станокта эшли белә.

Ә менә Екатерина Ефремова цех алдына килеп баскан һәрбер яңа эшне бик тиз үзләштерә. Ул элек имән мебельләр лаклаучы иде, соңыннан малярлык эшенә, йомшак диваннар, кушеткалар тышларга, корзинкалар үрергә, биллиард ясарга өйрәнде. Ватан сугышы башлангач, элек ирләр генә эшли торган фрезер станогында эшли башлады. Хәзер инде ул столярлык эшен дә башкара. Аның иптәше Шәйхуллина да аннан калышмый. Алар һәркайсы 8 әр профессия үзләштерделәр һәм нормаларын 200 процентка үтиләр.

Менә шушындый универсаль кешеләрнең булышлыгы белән цех үзенең бурычын уңышлы башкара һәм эштә зур оперативлык күрсәтә, Кызыл Армиянең 25 еллыгына кушылып алган йөкләмәләрен намус белән үти.

И. ФӘЙЗУЛЛИН.

КОЛХОЗ ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕР

ЧЕПЬЯ, 27 январь. **(Телефон буенча).** Сталин исемендәге авыл хуҗалыгы артеле членнары 1942 нче елда барлык авыл хуҗалыгы эшләрен үз вакытында тәмамладылар. Дәүләт алдындагы йөкләмәләр дә тулысынча үтәлде.

Бу колхоз көздән үк 1943 нче елның язгы авыл хуҗалыгы эшләренә әзерлеккә үзенең барлык көчен туплады. Колхозчылар батыр Кызыл Армиябез тарафыннан ирешелгән җиңүләр белән шатланып язгы чәчүгә әзерлекне үрнәк булырлык итеп алып баралар. Колхоз председателе иптәш Нәбиева колхозчы масса арасында булган күтәренкелекне эшкә туплый белә. Биредә хезмәт дисциплинасы ныгыганнан-ныгый бара.

Намуслы хезмәтнең матур нәтиҗәләре күренә башлады инде. Колхоз 716 центнер чәчүлек орлыкны чистартып, коры урынга салып куйды. Аларны район орлык тикшерү лабораториясендә тикшереп карагаңнан соң, чәчүлекнең тишелеше 98—99 процент булуы беленде. Ике чәчү машинасына, 40 сабанга, 27 тырмага, 4 культиваторга яхшы сыйфатлы итеп ремонт ясалды. 25 арба, җитәрлек кадәр сука камытлары һәм башка сбруйлар булдырылды. Колхозның тимерчесе иптәш Блинов ремонт эшендә зур тырышлык күрсәтте. Хәзер ул булышлык итү өчен күршедәге Сәрдек авылы колхозына китте.

Кышкы агротехника чараларының яхшы үткәрелүе, иген уңышын күтәрүнең мөһим чарасы булып тора. Колхозда 375 гектар мәйданда кар тотылуы, басуга 128 тонна тирес чыгарылуы, 38 центнер көл һәм 13 центнер кош тизәге җыеп куелуы колхозчыларның бу эшкә дә зур игътибар бирүләрен күрсәтә.



Директоры иптәш М кеев булган Н-че завод авыр машина төзелеше Наркоматының алдынгы предприятиеләреннән берсе. Рәсемдә: стахановчылар Мария Мамяникова һәм Любовь Суслова эш вакытында.

ТАСС фотохроникасы.

Киңәшмәдә

ТЕЛӘЧЕ, 27 январь. **(Телефон буенча).** Күптән түгел ВКП(б) райкомы язгы чәчүгә әзерлекнең барышы турында колхоз председательләренең һәм авыл советы председательләренең киңәшмәсен үткәрде. Биредә колхоз һәм авыл советы җитәкчеләре үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар һәм эштә булган җитешсезлекләрне бетерү турында сөйләштеләр.

Киңәшмәдә «Самолет № 2» колхозының язгы чәчүгә әзерлекне начар оештыруына аеруча тукталдылар. Бу колхозның (председателе иптәш Потапов) правление членнары кыш башлану белән тыныч күңеллелек настроениесенә бирелгәннәр. Узган елгы авыл хуҗалыгы эшләрен тизрәк төгәлләү өчен көрәшне туктатканнар. Шуның нәтиҗәсе буларак, колхозда әле 200 гектардан артык ашлык сугыласы бар. Язгы чәчүгә әзерлекнең дә темпы акрын.

Чәчү орлыгы әзерләнмәгән. Сугылган ашлык күп булуга да карамастан, орлыклык участокларның ашлыгы башка расходларга тотылган. Басуга тирес чыгару, кар тоту һәм көл җыю чаралары оештырылмаган. Машиналарга һәм сбруйларга ремонт башланмаган да әле.

Киңәшмә бу колхоздагы җитәкчеләрне эшлексезлек күрсәтүләре өчен каты тәнкыйтьләде. Эшне тиз көндә юлга салу чараларын билгеләде. Колхозда язгы чәчүгә әзерлекне барлык тармаклар буенча да яхшырту өчен анда ВКП(б) райкомыннан махсус кеше җибәрелде.

З. ИВАНОВ.

КАМЫТ ТӨЗӘТҮ МАСТЕРСКОЙЛАРЫ

ЧЕПЬЯ, 27 январь. **(Телефон буенча).** «Правда», «Ирек» һәм Киров исемендәге колхозларда камыт төзәтү мастерскойлары оештырылды. Аларда 200 дән артык камыт төзәтелде инде. Бу колхозлардагы мастерскойлар күрше колхозларның да камытларын төзәтәләр.

„ВАК-ТӨЯК"ЛӘРГӘ ИГЪТИБАР ИТМӘҮНЕН НӘТИҖӘЛӘРЕ

Иптәш Рохлин җитәкчелегендәге участок берничә айлар буе начар эшләмәде. Ярышта, заводтагы участоклар арасында ул октябрь аенда өченче урынны һәм ноябрь аенда икенче урынны алган иде. Бу айларда да участокта төрле кыенлыклар, кимчелекләр булды, әлбәттә, ләкин алар ничектер җиңел бетерелә килделәр.

Дөрес, кыенлыкларның күбесе төрле «вак-төяк» ләр аркылы килеп чыктылар. Ләкин иптәш Рохлин аларга артык игътибар итмәде. Производстводагы нәкъ менә шундый «вак-төяк» ләргә игътибар итмәү, ягъни, аларның ахыр чиктә нәрсә китереп чыгарасыларын алдан күрә белмәү —участокны соңыннан күңелсез хәлдә калдырды.

Декабрь ае килеп җитте. Участокның коллективы, иптәш Рохлин кебек үк, бер максатка—декабрьда беренчелекне яулап алуга омтылды. Ләкин декабрьның беренче көннәреннән үк эшләр бөтенләй башкача булып китте Участокның бер бүлеге графиктан төшеп калды. Иптәш Рохлин бу юлы да кыенлыкны җиңел генә җиңеп чыгарга уйлады. Ләкин хәл җитди иде. Ашыгыч рәвештә күрелгән байтак чаралар тиешле нәтиҗә бирмәделәр. Шуннан соң икенче, өченче, дүртенче кыенлыклар килеп тудылар. Декабрь урталарында инде бөтен участок авыр хәлдә калды Иптәш Рохлин бер өзеклек участогыннан икенчесенә ыргылды. Кайбер группаларда эшчеләр цехтан чыкмыйча тәүлекләр буе эшләделәр, ләкин хәл яхшырмады.

Иптәш Рохлин игътибар итмәгән, башта ук аларны җитди рәвештә бетерү чараларын күрмәгән, ә ашыгыч рәвештә, арыбире, җиңелчә генә ерып үтәргә теләгән ул «вак төякләр» нәрсәләр иде соң? Иптәш Рохлин участогында квалификацияле хезмәт таләп итүче бик күп санлы вак детальләр эшкәртелә. Бер группада 1—2 эшче эшкә чыкмый калдымы—икенче группада детальләрне эшкәртү өчен кирәкле материаллар булмый, өченчесендә полуфабрикатлар җитешми, дүртенчесендә—складтан материаллар китереп булмый,—нәтиҗәдә участокның барлык эше юкка югала Бу һәм моңа ошашлы бүтән кыенлыклар нәкъ декабрь аенда килеп тудылар. Участок бу кыенлыкларны җиңеп чыга алмады.

Группаларның берсендә детальләр эшкәртүче ике кеше эшкә килмәгәч, аларны алмаштырырлык кешеләр группада юк булып чыкты Ә һөнәр мәктәпләреннән килгән яшь эшчеләрне участокта түбәнрәк квалификацияләргә өйрәткәннәр. Әгәр дә иптәш Рохлин «алмаштыруы мөмкин түгел» дип саналган эшчеләр урынына яна, яшь кадрлар әзерләү эше белән җитди рәвештә шөгыльләнгән булса иде—бу группада хәзер өзеклек килеп тумаган булыр иде.

Икенче бер группада детальләрне эшкәртү өчен кирәк булган материаллар вакытлыча юк булып чыкты. Ә житешми торган мондый материаллардан башка да детальләр эшкәртүнең бүтән методларын кулланута алдан әзерлек алып бармаганнар. Җитәкчеләр мондый хәлнең килеп туачагын алдан күрә белергә тиешләр иде, чөнки участокка кирәк булган материалларның килми калу ихтималы турында сигналлар бер ай элек үк бар иде.

Өченче бер группада детальләр җитешмәүдән өзеклек килеп туды. Иптәш Рохлин тревога кузгатты:—безне тәэмин итүчеләр планны өзәләр! Поставщикларга бардылар. Алар Рохлинның тревогасына гаҗәпләнәләр генә. Аңа тиешле документларны күрсәттеләр: план буенча билгеләнгән барлык детальләр участокка тулысынча бирелгән.

Группада простой булуның сере бик гади иде. Иптәш Рохлин участогында гаять зур санда вак детальләр эшкәртелә. Эшкәртелү процессында алар бик зур юл үтәләр, төрле операцияләрдә, участокның берничә группасында һәм күрше цехта булалар. Ә инде бер операциядән икенчесенә күчүнең төгәл учеты булмаганлыктан, һәрбер операциядә диярлек югалтулар, ягъни яшерен брак булып торган икән Теге яки бу эшче, детальне бозгач та, аны просто чыгарып ташлаган. Элегрәк иптәш Рохлин участогында мондый югалтуларга игътибар итмәгәннәр, ә инде поставщиклар үз заказларының үтәлешен тикшерү эшенә яхшы тәртип керткәч тә, Рохлин участогындагы бу югалтулар бик тиз ачып салынганнар.

Кайбер материаллар участокка турыдан-туры складтан китертелә Ярдәмче эшчеләр аларны аз-азлап, кечкенә арбаларга төяп, турыдан-туры эш урыннарына ташыйлар. Барысы да үз тәртибендә кебек. Бу системаның нинди зарарлы ягы булсын? Ләкин менә, ярдәмче эшчеләрдән 3 иптәш, авыру сәбәпле, эшкә чыкмый калалар. Материаллар ташуда тоткарлыклар килеп туа. Мастерлар, бу хәлдән котылу өчен, материаллар ташырга квалификацияле эшчеләрне җибәрәләр. Бу хәл үзеннән-үзе планның өзелүенә китерә. Моңа тагын да өстәмә бер кыенлык килеп кушыла. Цехта яңа станокларга кабельләр үткәргәннәр, ә алар казылып урнаштырылган чокырларны яхшылап күмеп куймаганнар. Мондый чокырлы-чакырлы урыннардан арбалар йөртүе исә бик кыен.

— Цехның идәннәрен ни өчен соң әйбәтләп тигезләмисез?—дип сорыйлар механиктан һәм завхоздан

—Миндәге эшчеләр барысы да складтан материаллар ташуга күчерелгән булгач, аны кемнән эшләтим мин,—дип җавап кайтара завхоз Маслов.

— Миндәге ремонт эшчеләре дә шулай ук,—ди механик Симонов.

— Кабельләр куелганга бик күп вакыт үтеп китте бит инде!

— Ул чакта моңа баш җитми калган шул,—диләр икесе дә

Иптәш Рохлин үзе дә моңа үз вакытында игътибар бирмәгән.

Әнә шундый төрле «вак төяк» ләргә бармак аша карау цехны, ниһаять, авыр хәлгә төшерә.

Рохлин участогында хәзер мондый күңелсез хәл тәмам төзәтелде инде. Ләкин моның өчен күп кенә өстәмә көч һәм средстволар тотарга туры килде

Бу— барлык коллективлар өчен яхшы сабак булырга тиеш.

А. Алексеев,
Н-че завод.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

27 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

27 нче январьда **Воронеж** фронты гаскәрләре район үзәге һәм зур тимер юл станциясе **Горшечноены**, халык яши торган зур пунктлардан **Березово Колодезьны, Старо-Миловоены, Ново-Миловоены, 1 нче һәм 2 нче Городищены** алдылар.

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр район үзәге **Егорлыкскаяны** һәм тимер юл станциясе **Атаманны** алдылар.

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре район үзәге һәм тимер юл станциясе **Ново-Александровскаяны**, халык яши торган зур пунктлардан: **Средний Егорлыкны, Расшебатскаяны, Григориполисскаяны, Отрадо-Ольгинскоены** һәм тимер юл станциясе **Григорополисскины** алдылар.

Закавказье фронты гаскәрләре **Нефтегорск** шәһәрен һәм район үзәге **Апшеронскаяны** алдылар.

* * *

26 нчы январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төягән 150 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 6 сугыш припаслары складын һәм ягулык складын шартлаттылар, дошманның 2 батальонга якын пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Дон фронты гаскәрләре дошманның бүлгәләнгән группаларын кыруны дәвам иттерделәр. Сталинградның үзәк өлешенә якын урында Н-че частьның сугышчылары 1.350 немец солдатларын һәм офицерларын плен алдылар. Күрше участокта 2.000 гитлерчы, шул исәптән: командиры белән берлектә, немецларның элемтә армия полкы коралын ташлады. Сталинградтан төньяктарак безнең сугышчылар немец солдатларының һәм офицерларының аерым группаларын юк иттеләр.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр, ә көчләрнең бер өлеше белән дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Н-че берләшмә частьлары алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны, шул исәптән Егорлыкская станицасын алдылар. Егорлыкская өчен булган сугышта немецларның 3 танкысы һәм бер батальонга якын пехотасы юк ителде. Икенче бер участокта дошман танкларының һәм пехотасының зур көчләре контратакалар ясадылар. Бик каты сугыш нәтиҗәсендә дошман элекке позицияләренә алып ташланды. Немецларның 9 танкысы яндырылды һәм 3 самоход орудиесе юк ителде. Дошман гаять күп җанлы көчләрен югалтты.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар. Белокуракинодан көнбатыштарак Н-че берләшмә алга таба китте һәм халык яши торган 10 пунктны алды. Халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта немецлар контратакага ике батальонга якын пехота һәм 10 танк җибәрделәр. Сугыш алмаш-тилмәш уңыш белән барды. Кичкә таба безнең частьлар немецларны хәлсезләндерделәр, кискен атакага күчтеләр һәм бу пунктны алдылар.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар. Варваровка—Шилякино районында аз гына сугышканнан соң дошманның 5.000 солдаттан һәм офицердан торган, чолганып алынган бер группасы пленга бирелде. Коралларын ташлаган офицерлар арасында бер полковник, ике майор һәм бер капитан бар. Икенче бер участокта гвардия частьлары, алга таба барып, халык яши торган 3 пунктны алдылар һәм 400 гә якын гитлерчыны юк иттеләр. Бер танк, 3 танкетка, 11 орудие, 18 пулемет, инженерлык милекләре тутырылган бер склад һәм бер азык склады кулга төшерелде.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре уңышлы рәвештә алга бардылар һәм халык яши торган берничә пункттан немецарны бәреп чыгардылар. Н-че часть сугышчылары дошманга каршы сугышларның бер көне эчендә 9 танк, 26 автомашина, 11 орудие, күп пулеметлар, автоматлар, винтовкалар һәм сугыш припаслары кулга төшерделәр. 90 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. Икенче бер участокта гвардияче кавалеристлар халык яши торган берничә пунктны алдылар һәм бик күп трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Калинин өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның партизаннары дошманның автоколоннасына һөҗүм ясаганнар. Совет патриотлары йөк төялгән 18 автомашинаны юк иткәннәр, 137 немец солдатын һәм офицерын кырганнар. Трофейлар кулга төшерелгән. Икенче бер отрядның партизаннары халык яши торган бер пунктта дошман гарнизонына каршы сугышта 45 немец солдатын юк иткәннәр. Партизаннар мылтык һәм пулемет уты белән немецларның бер самолетын атып төшергәннәр.

* * *

Немец-фашист кабахәтләр Украина шәһәрләрен һәм авылларын җимерәләр, гражданнар халкын кыралар. 1942 нче елның декабрендә гитлерчылар Житомир өлкәсендә Славечно, Рудня, Тхорин, Бегунь; Городец, Рудня—Сырница; Юрово, Хочин һәм Нерга авылларын яндырганнар. Городецта немецлар 180 йортны, Лученки авылында 250 йортны, Славечнода 307 йортны юк иткәннәр. Рудня—Сырница авылында гитлерчы палачлар 40 кешене сарайга куып керткәннәр һәм тере көе яндырганнар. Сочинда фашист палачлар 55 яшьлек Дмитрий Дубровецны, 60 яшьлек Федор Игнатюкны, 70 яшьлек Мария Мельникны, 18 яшьлек Агриппина Гавриловины һәм башка колхозчыларны ерткыч төстә үтергәннәр.

* * *

Югославия партизаннары Жепче шәһәрен һәм тимер юл станциясен һәм Нови Шәһәрне алганнар. 7 станоклы пулемет, 200 винтовка, 100.000 патрон, бер бронепоезд, 60 вагон һәм башка төрле хәрби милекләр кулга төшерелгән Грагац, Ловинцы һәм Госпич районында Югославия патриотлары итальян оккупантларның берничә атакасын кире кайтарганнар. Дошманга каршы сугышларда партизаннар 2 төзек танк һәм башка трофейлар кулга төшергәннәр

ТӨНЬЯК АФРИКАДА ЧЕРЧИЛЛЬ БЕЛӘН РУЗВЕЛЬТНЫҢ ОЧРАШУЫ

ЛОНДОН, 27 январь. (ТАСС). Англиянең информация министрлыгының игълан ителгән рәсми белдерүендә Бөек Британиянең баш министры Черчилльнең һәм Америка Кушма Штатлары президенты Рузвельтның Франция Марокkосындагы Касабланка янында очрашканлыклары әйтелә. Очрашуда һәр ике илнең штаб начальниклары һәм башка киңәшчеләр катнашканнар. Белдерүдә болай диелә:

«Америка Кушма Штатлары президенты һәм Бөек Британия баш министры Касабланка якынында 14 нче январьдан башлап киңәшмә алып бардылар. Аларны һәр ике илнең штаб начальникларыннан берләшкән бер группа озата барды. Бу группада Америка Кушма Штатларыннан Америка армиясе штабы начальнигы генерал Джорж Маршалл, Американың хәрби диңгез флоты баш командующие адмирал Кинг, Америка армиясенең хәрби һава көчләре командующие генерал-лейтенант Арнольд һәм Бөек Британиядән адмиралтействоның беренче лорды флот адмиралы Дадли Паунд әфәнде, империянең генеральный штабы начальнигы генерал Аллан Брук әфәнде, һава көчләре штабы начальнигы авиация баш маршалы Чарльз Портал әфәнде бар иде. Аларның ярдәмчеләре сыйфатында түбәндәгеләр катнаштылар: Америка армиясенең интендантлык хезмәте начальнигы генерал-лейтенант Сомервелл, Англиянең Вашингтондагы берләшкән миссиясе башлыгы фельдмаршал Джон Дилл әфәнде, десант операцияләре командующие вице-адмирал лорд Луис Моунтбэттен, оборона министры янындагы штаб начальнигы генерал-лейтенант Хастингс Исмэй әфәнде, шулай ук һәр ике илнең күп кенә штаб офицерлары. Аларга Мэрфи әфәнде һәм Макмиллан әфәнде, союзникларның Төньяк Африкадагы экспедиция көчләре баш командующие генерал Эйзенхауэр, союзникларның Төньяк Африкадагы хәрби диңгез экспедиция көчләре командующие флот адмиралы Эндрью Кеннингхэм әфәнде, союзникларның Төньяк Африкадагы экспедиция көчләренең авиация командующие генерал Спаатс, Америка армиясе генералы Кларк, Урта Көнчыгыш штабыннан генерал Гарольд Александер әфәнде, авиация маршалы Артур Теддер әфәнде һәм Америка армиясе генерал-лейтенанты Эндрьюс визит белән килделәр. Президентны Гарри Гопкинс әфәнде озата барды һәм аларга Аверелл Гарриман да кушылды. Баш министрны Англиянең сугыш заманы транспорты министры лорд Лезерс озата барды.

Берләшкән штаблар 10 көн буена һәрвакыт утырышларда булдылар, көненә икешәр-өчәр тапкыр очраштылар, сөйләшүләрнең барышы турында тәнәффес вакытларында президентка һәм баш министрга докладлар ясадылар. Киңәшмәдә дөньядагы барлык сугыш мәйданнарындагы хәлгә анализ ясалды һәм диңгездә, һавада һәм корыда сугышны тагын да нәтиҗәлерәк итеп алып бару өчен барлык ресурслар тикшерелде. Моңа кадәр бу ике союзник арасында беркайчан да әле шул кадәр озакка сузылган киңәшмә булганы юк иде. 1942 нче елның ахырында вакыйгаларда булган ачыктан-ачык унайлы борылыштан иң күп күләмдә файдалану максаты белән Германиягә, Италиягә һәм Японияга каршы 1943 нче елгы кампания вакытында үткәрелергә тиешле хәрби планнар һәм чаралар уңае белән һәр ике илнең җитәкчеләре һәм тиешле штаблар арасында тулы килешүгә ирешелде.

Баш министр Сталин президент һәм баш министр белән очрашу өчен чын күңелдән чакыру алды. Әгәр ул килгән булса иде, очрашу шактый гына дәрәҗәдә көнчыгыштарак булган булыр иде. Ләкин зур һөҗүм барганлыктан һәм бу һөҗүмгә Верховный Баш Командующий сыйфатында Сталин үзе җитәкчелек иткәнлектән, ул хәзерге вакытта Россиядән китә алмады. Президент һәм баш министр бөтен коры җир фронтында Россиянең гаять зур сугыш авырлыгын уңышлы рәвештә үз җилкәсендә күтәреп баруын аңлыйлар һәм аларның төп максаты, аеруча унайлы районнарда дошманны мөмкин кадәр тагын да авыррак көрәшкә тарту юлы белән, рус армияләре өстендәге авырлыкның мөмкин кадәр күп өлешен читләтүдән гыйбарәт булды. Хәрби тәкъдимнәр турында баш министр Сталинга тулы информация бирелде.

Президент һәм баш министр генералиссимус Чан-Кай-ши белән элемтә тоттылар. Алар аңа Кытай тарафыннан гомуми эш өчен алып барыла торган бик яхшы һәм каты көрәштә ярдәм күрсәтү максаты белән үзләре үткәрә торган чаралар турында информация бирделәр. Президентның һәм баш министрның очрашуы нәтиҗәсендә штаблар начальникларының берләшкән группасы белән киңәшү һәм генерал Жиронын генерал де Голль белән очрашуын оештыру өчен генерал Жироны чакырырга мөмкинлек булды. Генераллар икесе дә бер-берләре белән җентекле консультация алышалар.

Президент, баш министр һәм штаблар начальникларының берләшкән группасы, үзләренең 1943 нче елгы һөҗүм кампанияләре планнарын эшләүне тәмам иткәннән соң хәзер бу планнарны актив һәм килешкән төстә тормышка ашыру өчен таралыштылар.

24 нче январь, 1943 нче ел».

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДА

ЧАҢГЫ ЯРЫШЛАРЫ

ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты карары буенча 14 нче февральдән алып 1 нче мартка кадәр Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган профсоюз-комсомол кроссы үткәреләчәк.

Ярыш программасы буенча БГТО шартларына туры китереп, үсмер яшьләр чаңгыларда 3 километр араны, үсмер кызлар 2 километр араны шуып үтәргә тиешләр. Ирләр өчен I нче һәм II нче баскыч ГТО комплекслары буенча 10 километр ара расланды. Хатын-кызлар өчен I нче баскыч ГТО шартлары буенча 3 километр, II нче баскыч ГТО шартлары буенча 5 километр ара расланды.

(ТАСС).

Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә Воронеж өлкәсендәге Добринский районы Ильич исемендәге авыл хуҗалыгы артеле колхозчылары бер взвод кызылармеецларны баштанаяк киендерергә, һәрбер сугышчыга кыска тун, киез итек, бүрек, бияләй. оек, кулъяулыклар, кисет бирергә йөкләмә алдылар.

Колхозчылар сугышчылар өчен киемнәр тегә башладылар һәм Воронеж өлкәсенең барлык колхозчыларын үзләреннән үрнәк алырга чакырдылар.

* * *

Сталин исемендәге үзәк физкультура дәүләт институты коллективы гади укыту-фәнни эшләрдән тыш ватан сугышы вакытында хәрби физик хәзерлекнең барлык төрләре буенча 219.000 сугышчыны, командирны һәм инструкторны өйрәтеп чыгарды.

* * *

Урал кочегаркасының шахтерлары Кызыл Армия көненә планнан тыш 40 эшелон күмер әзерлиләр. «Коспашуголь» (Кизел) трестының 7—8 нче номерлы шахталары коллективлары планнан тыш 1.050 тонна күмер биреп, планнан тыш тагын 3.000 тонна күмер чыгарырга булдылар.

* * *

Алтай краеның авыл комсомол оешмалары кар тоту буенча ике атналык башладылар. Комсомолецлар 1 нче февральгә кадәр барлык көзге чәчү мәйданында кар тотуны үткәрергә йөкләмә алдылар.

Металлургия комбинаты төзелешендә (Магнитогорск) яшь эшчеләр өчен стахановчылар кабинеты оештырылды. Бу кабинетта беренче чиратта нормасын үтәмәүче эшчеләр һәм ФЗӨ мәктәпләре укучылары курсы үткәрелә.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

ЯФ625 «Красная Татария» һәм «Кызыл Татарстан» вздательствосының Але... исемендәге типографиясе № Заказ 179